Более того, демонстрация советских военных песен на английском языке также не оставит детей равнодушными и заставит гордиться культурным наследием родной страны.

Знание языка — это готовность и способность вести диалог с другими людьми, достигать в нём взаимопонимания, находить общие цели и сотрудничать для их достижения.

Таким образом, овладение способностью к межкультурной коммуникации позволит не только поглощать, но и отдавать, обмениваться бесценным историческим и культурным опытом поколений и национальностей, стран и общностей. Вот на что должен быть способен патриот, владея иностранным языком, — нести культурное и историческое наследие своей страны.

## «Туган илем – алтын бишек»

(мәктәпкә әзерлек төркеме өчен белем бирү эшчәнлеге)

*Егорова Г. А., I квалификацион категорияле тәрбияче,*
*МБМБУ - «Мамадыш шәһәре 11 нче «Ландыш» балалр бакчасы»*

**Максат:** Якташ шагыйрьләребез иҗаты аша «Кече Ватан»га карата мәхәббәт хисе формалаштыру.

**Тәрбия бурычы:** Якташ шагыйрьләребез иҗаты аша балаларларда нәфис сүзгә кызыксыну, туган якка сөю хисе тәрбияләү.

**Үстерү бурычы:** балаларның кабул итүләрен, кызыксынуын, татар телендә сөйләм күнекмәләрен үстерү.

**Белем бирү бурычлары:** Туган як турында балаларның күзаллаулар формалаштыру.

**Төп белем бирү өлкәсе:** танып белү

**Интеграль белем бирү өлкәләре:** социаль-коммуникатив, сөйләм үсеше, иҗади сәнгать.

**Методик алымнар:** уен, әңгәмә, сораулар, нәфис сүз, музыка тыңлау.

**Җиһаз һәм материаллар:** Нәкыя Йосыпова сүзләренә Фәнис Нәбиуллин көенә язылган “Әй, Мамадыш, Мамадыш” җырының аудиоязмасы, интерактив такта, Нәкыя Йосыпова, Мансур Сафин, Рафаил Газизов фотосурәте, Мамадыш шәһәре курсәтелгән слайдлар.

**Сүзлек өстендә эш:** Кече Ватан, якташ шагыйрьләребез, Нократ буйлары, Пузанка таулары

**Алдан башкарылган эш:**

1. ”Туган як” музеена экскурсия.
2. Мамадыш шәһәре турында фотосүрәтләр карау.
3. Туган як турында мәкальләр, шигырьләр, җырлар өйрәнү, тыңлау.
4. Якташ шагыйрьләребез иҗаты белән таныштыру.

**Эшчәнлек төзелеше:**

1. Психологик җайлашу
2. “Туган җир” турында әңгәмә
3. “Әй, Мамадыш, Мамадыш” җырын тыңлау
4. М.Сафинның «Мамадышка мәдхия» исемле шигыреннән өзек уку
5. “Мәкаль әйтеш” уены
6. Р. Газизов иҗаты белән дә таныштыру.
7. Йомгаклау

### Эшчәнлек барышы:

*Экранда Мамадыш шәһәренең күренекле урыннары төшерелгән слайд*

**Тәрбияче:** Хәерле көн, балалар! Бүген без сезнең белән туган ил, туган җир турында сөйләшербез. Ә нәрсә соң ул туган җир, нинди була ул? Туган җир дигәч, сезнең күз алдына

нәрсәләр, кемнәр килә? *(Туган ил ул әни, әти, әби, бабай, туган өй, туган тел, балалар бакчасы, һ.б.)*

**Тәрбияче:** Әйе, балалар. Һәр кешенең үз туган җире бар - ул **Ватан** дип атала. Кешенең анасы бер генә булган кебек, Ватаны да бер генә. Ә Олы Ватан Кече Ватаннан башлана. Нәрсә соң ул Кече Ватан? (Индивидуаль һәм күмәк җаваплар.) Безнең өчен ул – Мамадыш шәһәре. Кече Ватан ул – туган шәһәр, туган өй, әти-әни, әби-бабай, туганнар, күршеләр... Кече Ватан ул – уйнап үскән урам, елга-күлләр, кырлар, урманнар, кошлар. Ватанны һәркем үзенчә ярата, хөрмәт итә. Рәссамнар туган җиренә багышлап рәсем ясый, язучылар хикәяләрдә сурәтли, шагыйрьләр шигырьләр чыгара.

*"Әй, Мамадыш, Мамадыш" җырының аудиоязмасы яңгырый.*
*(Нәкыя Йосыпова сүзләре , Фәнис Нәбиуллин көе)*

**Тәрбияче:** Балалар, игътибар белән җырны тыңлагыз әле. Ул нәрсә турында икән? Бу җыр сезгә танышмы? Җырның сүзләрен кем язган? (Балалар җавабы. Балаларны активлаштыру.)

*Экранда Нәкыя Йосыпова фотосурәте*

**Тәрбияче:** Бик дөрес, туган ягыбыз Мамадыш төбәге әнә шулай дәртле һәм моңлы җырларда искә алына. Җырның сүзләрен якташыбыз Нәкыя Йосыпова язган. «Әй, Мамадыш, Мамадыш» җыры – районның гимны булып тора.

**Тәрбияче:** Әй Мамадыш, Мамадыш,
Чит җирдә йөртмә ялгыш.
Туган -үскән илдә генә
Бәхетле була язмыш.... дип җырлана. Бу җырны башкарган һәм тыңлаган һәркем, ямьле Нократ буйларын, болын һәм тугайларны, калын урманнарын, Пузанка тауларын күз алдыннан китерә торгандыр.

**Тәрбияче:** Мамадышның табигате бик матур. Аның турында бик күп җырлар, шигырьләр язылган. Хәзер мин сезгә якташ шагыйребез Мансур Сафинның «Мамадышка мәдхия» исемле шигыреннән өзек укырмын.

*Экранда Мансур Сафин фотосурәте*

Игътибар белән тыңлагыз!
Сандугачлар мине сагынгандыр,
Юксынгандыр Нократ җилләре.
Мәңге балкыр Мамадышта таңнар,
Аллandырып сагыш җилкәнен.

Шигырьнең исеме нинди? *(«Мамадышка мәдхия»)* Шигырьдә нәрсә турында сөйләнә? (*Туган як, туган җир*). Туган ягыбызга карата нинди хисләр чагыла? (*Ярату, сагыну, юксыну*)

**Тәрбияче:** Димәк, кайларда гына йөрсәң дә, туган як күңелгә иң якыны һәм иң кадерлесе. Сез минем белән килешәсезме? Ни өчен? ((Балалар җавабы. Балаларны активлаштыру.)

**Тәрбияче:** Балалар, әйдәгез "Мәкаль әйтеш" уены уйнап китәбез. Туган ил турында нинди мәкальләр беләсез икән.

- Туган илем – алтын бишек.
- Туган илем – туган өем
- Туган илем – туган телем
- Туган ил бер генә, кадерен бел генә.
- Иле барның теле бар.
- Илсез кеше телсез сандугач.
- Иленнән аерылган, канаты каерылган.

**Тәрбияче:** Булдырдыгыз балалар. Туган ил турында бик күп мәкальләр беләсез икән.

**Тәрбияче:** Төбәгебез талант иярләренә бик бай. Ихтирамга лаек булган, яраткан шагыйребез Рафаил Газизов иҗаты белән дә таныштырып китәсем килә сезне. Сез әзерме?

*Экранда Рафаил Газизов фотосурәте*

**Тәрбияче:** Рафаил Газизов – Татарстан язучылар берлеге әгъзасы, Ильдар Юзеев исемендәге әдәби премия лауреаты. Рафаил абыйның Туган җире - Мамадыш районы Кече Кирмән авылы.

Иҗатында туган илгә, туган җиргә мәхәббәт, патриотик хисләргә бай булган шигырьләре шактый. Тыңлап карагыз әле:

Бу күзләрем – ак каеннар моңы,
Сөйләшүем - чишмә сагышы
Мин – авылның иген басуыннан
Йолкып китерелгән арышы.

**Тәрбияче:** Шигырь сезгә охшадымы? Сез ничек уйлыйсыз, сүз кайсы авыл турында бара? Ни өчен? (Балалар җавабы. Балаларны активлаштыру.)

**Тәрбияче:** Булдырдыгыз, балалар. Сорауларга дөрес һәм матур итеп җавап бирдегез.Сез миңа бик ошадыгыз.

**Тәрбияче:** Әйтегез әле, без бүген белән нәрсә турында сөйләштек? (Кече Ватан, Туган ил, туган җир, якташ шагыйрьләребез турында). Кайсы якташ шагыйрьләр иҗаты белән таныштык? (Нәкия Йосыпова, Мансур Сафин, Рафаил Газизов). Бүгенге эшчәнлек сезгә ошадымы?

**Тәрбияче:** Без туган ягыбызга, аның гүзәл табигатенә дан җырлаучы якташ шагыйрьләребез иҗаты белән таныштык. Димәк, һәр кешенең дә туган җире бар. Кеше туган җирсез, туган илсез яши алмый. Һәр кешегә туган җир бик кадерле була. Сез үскәч тә, үзегезнең туган җирегезне яратырсыз, хөрмәт итәрсез дип ышанып калам.

## «Минем Ватаным Россия»

(квест – уен)

МБМББУ "Балтач №2 балалар бакчасы"
Тәрбиячеләр: Газимова Р. Р.
югары квалификацион категоря,
Бариева З. Р. беренче квалификацион категоря

**Балаларның яше**: зурлар төркеме (5-6 яшь)

**Максат:** Квест – уен кулланып балаларны актив эшчәнлеккә кертү чаралары буенча патриотик һәм гражданлык хисләрен формалаштырырга ярдәм итү.

**Бурычлар:**

**Белем бирү бурычы:** Балаларның туган ил - Россия турында белемнәрен гомумиләштерү һәм системалаштыру. Кече ватанның, Россиянең символикасы, табигате, бәйрәмнәр турында белемнәрне ныгыту.

**Тәрбия бурычы:** Россиягә, үзеңнең кече Ватаныңга - мәхәббәт, патриотик хисләр тәрбияләү.

**Үстерү бурычы:** Туган илгә кызыксынуны, күзәтүчәнлекне, игътибарны, логик фикерләүне үстерүгә ярдәм итүче шартлар тудыру.

**Төп белем бирү өлкәсе:** танып белү үсеше.

**Интеграль белем бирү өлкәләре:** сәнгәти- эстетик үсеш, сөйләм үсеше, социаль- коммуникатив үсеш.

**Методлар алымнар һәм чаралар:** презентация куллану, үстерелешле әңгәмә, сораулар, квест-уен, дидактик уеннар, сюрприз момент.

**Җиһазлар:** карта-маршрут, глобус, хат, "Дөрес төзе", "Яртысын тап" дидактик уеннар, бәйрәмнәр рәсемнәре презентациясе, хайван һәм үсемлек рәсемнәре, аудио язма (гимн России сл. С.В.Михалкова, муз. А.В.Александрова).

**Сүзлек өсендә эш:** глобус, видео оператор, квест, гимн.

**Алдан үткәрелгән эш:** презентация ясау, үстерелешле әңгәмә уздыру, дидактик уеннар уйнау, күзәтүләр, матур әдәбият уку, бәйрәмнәр, хайваннар һәм үсемлекләрнең рәсемнәрен карау.

**Квест-уенның төзелеше:**

**I.Кереш өлеш.**

1. Сюрприз-момент – хат килә, темага кызыксыну уяту.

**II.Төп өлеш.**

1.Глобус янында Россия турында үстерелешле аралашу.

2. Квест - уен сәяхәт, аның максаты, тәртибе турында мәгълүмат бирү.
3. 1 нче станция- “Мин сорармын, ә син җавап бир!”
4. 2 нче станция- - Россиянең дәүләт символлары.
5. 3 нче станция- - Россиянең рәсми булмаган символлары.
6. 4 нче станция- “Россия бәйрәмнәре”
7. 5 нче станция - “Туган як табигате”

**III.Йомгаклау өлеше.** Кыскача анализ.

**Квест-уенның барышы:**

- Дусларым, бүген минем электрон почтама Африка илләрендә яшәүче балалардан хат килде. Әйдәгез бергәләп укыйк әле.

*"Сәлам, дуслар, без Африка илләрендә яшибез. Без сезнең илегез –Россияне глобуста күрдек, ул бик зур. Һәм без сезнең ил турында: табигате, бәйрәмнәре, дәүләт символлары турында белергә бик кызыксындык. Безнең белән үзегезнең ил турында белгән белемнәрегез белән уртаклашсагыз без бик шат булыр идек. Уңышлар сезгә!».*

-Балалар, без башка ил балаларына үзебезнең туган илебез турында белергә ярдәм итә алырбызмы? *(Балалар җавабы)*

- Безгә бүген максатыбызга ирешергә квест – уен ярдәм итәр.

- Фикерләрегезне әйтегез әле, туган илебез-Россия турында белгәннәребезне ничек итеп башка илдәге дусларыбызга җиткерә алабыз? *(Балалар җавабы)*

-Дөрес, балалар, хәзерге вакытта төрле илләргә хәбәрне җиткерү ысуллары бик күп. Бүген без дә үзебезнең квест - уен сәяхәтебезне төшереп бару өчен видео оператор чакырдык. *(Видео оператор сәяхәт барышын төшереп бара.)*

-Глобуска игътибар белән карагыз, анда безнең илебез - Россия дә сурәтләнгән. Әйдәгез бергәләп глобуста илебезне эзләп табыйк, күрсәтик әле. *(Бергәләп эзләп табалар.)* Күргәнебезчә, Россия - дөньядагы иң зур ил. Ул шундый зур, әгәр дә без читтән икенче читенә барырга теләсәк, иң тиз поезда да бу юл бер атна вакытны алачак, ә самолетта көне буе очарга туры киләчәк.

- Квест - уен сәяхәтне башларга сез әзерме? *(Балалар җавабы)* Безнең уен “Минем Ватаным-Россия” дип атала. Уенның максаты: башка илдә яшәүче балаларны туган илебез белән таныштыру буенча сорауларга дөрес җаваплар табу. Уенның шарты: 5 бирем үтәргә кирәк. Һәр бирем пункты (1-5) маршрут картасында билгеле бер сан белән билгеләнгән, Бер пункттан икенчесенә күчү өчен биремне дөрес үтәп, команда җавап карточкасы ала. Бары тик 5 сынауны да дөрес узып кулда 5 җавап карточкасы булгач кына, без Африка илендәге балаларга безнең ил белән танышу өчен җавап хаты җибәрә алабыз,

**1 нче станция- “Мин сорармын, ә син җавап бир!”**

Балалар, сез Россия территориясе турында нәрсә беләсез? *(Россия дөньядагы иң зур ил, дөньядагы бер генә илнең дә Россия кебек зур территориясе юк. Безнең илнең бер очында кешеләр йокларга ятканда, икенчесендә иртә башлана. Бер яктан икенче якка барып җитәр өчен поездда 7 көн йөрергә, ә самолетта тәүлеккә якын очарга кирәк. Туган илебез территориясе бик күп төрле, анда бик күп диңгезләр, елгалар, таулар, чүлләр, сазлыклар һәм бик күп хайваннар бар.)*

Сораулар:

1. Без яшәгән илнең исеме ничек?
2. Туган илебезнең башкаласы ничек атала?
3. Россиядә яшәүче кешеләрнең исемнәре ничек?
4. Россиянең дәүләт символлары нәрсә ул?
5. Россиянең Президенты кем?

- Балалар, Россия-безнең зур Ватаныбыз. Һәркайсыгызның үз кечкенә Ватаны бар. Бәлки, сезнең берәрегез кечкенә Ватанның нәрсә икәнен беләдер? *(Балалар җавабы)*

- Туган илебез- безнең район. Аның исеме ничек? *(Балалар җавабы)*

- Балалар, районыбызның нинди истәлекле урыннарын атый аласыз? *(Балалар җавабы)*

Шулай итеп сез беренче биремне башкардыгыз. Беренче җавап картасын алыгыз.

**2 нче станция- - Россиянең дәүләт символлары.**

- Балалар, Россиянең дәүләт символы нәрсә икәнен искә төшерик.

Герб нәрсә ул? *(Балалар җавабы)* (*Герб-дәүләт эмблемасы. Ул барлык мөһерләрдә, акча билгеләрендә: кәгазь һәм металл мөһерләрдә сурәтләнә. Паспортларда һәм документларда.)*

-Россия флагында өч горизонталь полоса бар. Нинди төсләр дә алар? *(Балалар җавабы*)(Ак төс тынычлыкны һәм җан сафлыгын, зәңгәр тугрылыкны һәм хакыйкатьне, кызыл батырлыкны һәм мәхәббәтне аңлата.)

-Россиянең символы булып Гимн тора. Россия гимны-барлык дәүләт бәйрәмнәрендә һәм тантаналы чараларда башкарыла торган тантаналы җыр. Гимнны һәрвакыт басып тыңлыйлар. Балалар, хәзер бездә сезнең белән басып гимнны тыңлыйк. *(Басып гимнны тыңланыла.)*

- Дусларым, дәүләтебез символлары буенча "Дөрес төзе" дидактик уенын тәкъдим итәм. *(Балалар ике төркемгә бүленәләр. Беренче төркем өчен бирем: өлешләрдән флаг җыю. Икенче төркемчә өчен бирем: өлешләрдән Россия гербын җыю.)*

- Яхшы, сез бу эшне башкардыгыз. 2 нче җавап картасын алыгыз.

**3 нче станция- - Россиянең рәсми булмаган символлары.**

-Балалар, Россиянең рәсми булмаган символлары нәрсә икәнен искә төшерик? *(Каен, гармунлы аю, самовар, матрешка, балалайка, читек, коймак, Кремль һ.б.).*

- Хәзер мин сезгә "Яртысын тап" дигән дидактик уен уйнарга тәкъдим итәм. *(балалар уйный)*

-Яхшы, сез бу биремне дә башкардыгыз. 3 нче җавап картасын алыгыз.

**4 нче станция- "Россия бәйрәмнәре"**

-Безнең киләсе станциябез "Россия бәйрәмнәре" дип атала. Балалар, безгә экранга игътибар белән карарга һәм бәйрәмне дөрес итеп исемнәрен атарга кирәк. *(Экранда балалар өчен бәйрәмнәрнең фотолары тәкъдим ителә (Яңа ел, Раштуа, Пасха, Масленица, 23 февраль – Ватанны саклаучылар Көне, 12 июнь – Россия көне, 4 ноябрь – Халыклар бердәмлеге көне, Җиңү көне). Балалар календарь бәйрәмнәрне атыйлар.)*

- Яхшы, сез бу сынауны да башкардыгыз. 4 нче җавап картасын алыгыз.

**5 нче станция - "Туган як табигате"**

-Киләсе бирем туган як табигатенә багышлана. Безнең өстәлләрдә рәсемнәр урнаштырылган, сезгә сорауны тыңларга һәм җавапны дөрес итеп рәсемнәр арасыннан сайлап алырга кирәк.

1. Кайсы агач рус гүзәле дип атала? *(Каен)*
2. Һаваны чистарту буенча рекордчы агач? *(Тирәк)*
3. Нинди кошны урман санитары диләр? (*Тукран)*
4. Яз хәбәрен алып килүче кош? *(Сыерчык)*
5. Яраларны һәм җәрәхәтләрне дәвалаучы юл буенда үскән дару үсемлеге? *(Бака яфрагы)*
6. Сәламәтлеккә зарарлы гөмбә? *(Чебен гөмбәсе)*
7. Безнең районда нинди елга ага? *(Шушма)*
8. Нинди хайваннар йоклый? *(Аю, керпе)*

-Яхшы, сез бу биремне дә башкардыгыз. 5 нче җавап картасын да алыгыз.

Безнең квест -уен сәяхәтебез ахырына якынлашты. Безнең кулда уенның шарты буенча 5 җавап карточкасы җыелды. Безнең видео оператор да бик тырышып эшләде, аңа зур рәхмәт. Ул төшереп барган видио язманы Африка илләрендә яшәүче балаларнын электрон почталарына саласы гына калды. Ул эшне мин үзем башкарырмын. *(Бергәләп салуны да уйнарга була. Икенче көнне балаларга Африка илләре балаларыннан килгән "Рәхмәт хаты"белән тапшырырга була.) (Квест-уен тәмамлангач, тәрбияче балаларга смайлик сайларга тәкъдим итә: уен ошаган булса - күңелле смайлик алыгыз, ошамаса- күңелсез смайлик.Балалар үз сайлауларын аңлаталар.)*

-Ә бу смайликлар сезгә безнең гадәти булмаган сәяхәтебезне искә төшерсен, кайткач әти-әниләрегез белән дә уен-сәяхәт турында сөйләшерсез.

**«Музей педагогикасы аша балаларга патриотик тәрбия бирү»**

*Гәрәева Г.Р. , Шәрифуллина Л.Р.,*
*югары квалификацияле категорияле тәрбиячеләр,*
*34 нче санлы «Салават күпере» балалар бакчасы, Алабуга шәһәре.*

“Балалык – кеше тормышының иң мөһим чоры, ул – киләчәк тормышка әзерлек кенә түгел, бәлки чын, якты, үзенә генә хас кабатланмас тормыш. Бүгенге нәнинең нинди кеше булып үсүе сабыйның балачагы ничек үтүенә, балалык елларында аны кем тәрбияләвенә, әйләнә -тирә мохиттән аның аңына һәм йөрәгенә нәрсә сеңүенә бәйле”, – дигән В.А. Сухомлинский.

Балаларга әхлакый - патриотик тәрбия бирү балалар бакчасында төп максатларның берсе булып тора.

Патриотизм хисе эчтәлеге буенча күпкырлы: туган якка мәхәббәт, үз халкың, аның тарихы белән горурлану, үз илеңнең байлыгын арттыру һәм аны сакларга теләк булдыру һ.б.

Патриотик тәрбия бирүнең бер алымы - туган як тарихын өйрәнү. Туган як тарихын өйрәнү балаларга үз төбәкләрендә яшәгән кешеләр турында күбрәк белергә, якыннан танышырга мөмкинлек бирә.Аларның тормыш-яшәешләре балаларда соклану һәм горурлану хисләре уята, өлкән буын кешеләренә карата хөрмәт тәрбияли.

Балаларда туган илгә мәхәббәт, халкыбызның үткәндәге истәлекләрен хөрмәт итү, хәзерге казанышларына ихтирам һәм горурлык хисләре, милли аң тәрбияләүдә, балаларга патриотик тәрбия бирүдә музейлар зур әһәмияткә ия.

Бүгенгәчә бала өчен мәгълүмат чыганагы булып китап, рәсемнәр, тәрбияче сүзе тора. Ә шулай да аларны тагын да кызыксындырырга уйласак коммуникатив технололгияләр ярдәмгә килер. Шуңа да хәзерге педагоглар балаларны кызыксындыру, аларның игътибарын җәлеп итү өчен төрле алымнар уйлап табарга – шул ук мәгълүмати технологияләрне үзләштерергә һәм аларны укыту – тәрбия процессында кулланырга тырышалар. Заман үз таләпләрен куя: бүгенге көндә укыту-тәрбия процессына яңа технологияләрне кертеп җибәрү төп мәсьәлә булып тора. Менә шушы методика кысаларында балаларны үз тирәңә туплап, аларда кызыксыну сүрелмәслек итеп оештырырга кирәк дип саныйбыз. Һәр баланың белем үзләштерүгә сәләте төрлечә була. Кайбер балаларда ишетеп истә калдыру дәрәҗәсе өстенлек алса, күпчелек балаларда күреп истә калдыруы өстенлек алган була. Шуларны исәпкә алып без үз эшчәнлегебез барышында 5-7 яшьлек балалар өчен “Идел буе халыклары музее” дип исемләнгән дидактик әсбап булдырдык.

Бу әсбапны рус, татар, удмурт, мари халыклары, аларның тормыш – көнкүреше белән танышу, үзләштергән белемнәрне йомгаклау максатыннан, танып – белү белем эшчәнлегендә кулланабыз. Әлеге әсбап аша балаларның белемнәрен тикшереп, анализ ясап була.

**Максат:** Идел буе районнарында яшәүче рус, татар, удмурт, мари халыкларының яшәү рәвеше, гореф - гадәтләре турындагы күзаллауларны киңәйтү.

**Бурычлар:**

- тәрбияләнүчеләрнең Идел буе халыклары символикасы, гореф-гадәтләре, милли ашлары, костюмнары һәм орнаментлары турында белемнәрен ныгыту;
- Идел буе халыклары мәдәнияте һәм гореф - гадәтләре турында күзаллауларны киңәйтү;
- балаларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү, сүз байлыгын баету һәм активлаштыру;
- толерантлык, Идел буе халыкларына һәм аларның гореф-гадәтләренә хөрмәт хисе формалаштыру.

Дидактик әсбапның алгы өлеше татар, рус, мари, удмурт халыкларның өй эче бизәлешен чагылдыра, анда бу халыкларның милли киемнәре кигертелгән курчаклар урнаштырылган. Әлеге бизәлешләр һәм милли киемнәр балаларга курчакларның кайсы халык милләтенеке булуын ачыклап истә калдырырга ярдәм итә.

Дидактик әсбапның ян - як, өс, арт өлешләрендә һәр халыкның туган ягы, тарихы, символикасы, бәйрәмнәре һ.б. турында төсле рәсемнәр белән мәгълүматлар тупланган кечкенә

китапчыклар, милли ризыкларын, киемнәрен, бизәкләрен истә калдыру өчен ясалган пазллар, доминолар, лото һәм буягычлар урнаштырылган:

“Китапчык - Татарстан”, “Китапчык – Россия”, “Китапчык – Марий Эл”, “ Китапчык – Удмуртия”, “Татар орнаментлары”, “Трафарет”, “ Киемне бизә”, “Халыклар көлмәге”, “Буяу өчен рус курчаклары”, “ “Курчакны киендер”, “Удмурт бизәкләре”, “Матур итеп бизә”, “Парын тап” яки “Бизәкне җый”, “Милли ризыклар”.

Конвертлардагы уеннарның тышына кайсы халыкка кагылышлы булуына карап, әлеге халыкның ораменты урнаштырылган. Конверт эчендә уенның кагыйдәләре дә бар. Кайбер уеннарны тәкъдим итәбез:

**Д/у “ Халыклар күлмәге”**

Уен халык бизәкләрен өйрәнү өчен ясалган. Лото билгеле бер темага багышланган “кояш” формасында (мәсәлән, гжель бизәге), аның “нур”ларына төрле халыклар сарафаннарын кигән кызлар төшерелгән.

Уенның максаты – туры килгән “нур”ларны табып урнаштыру.

Уенның бурычлары: балаларның “Халык һөнәрләре” темасы буенча логик фикерләү сәләтен, игътибарлылыгын үстерү; эстетик сыйфатлар формалаштыру, балаларның белемнәрен активлаштыру.

Уенда рәсемне кем беренче җыеп бетерә, шул җиңүче була. Уенда бердән алып өчкә кадәр бала катнаша ала.

**Д/у “Татар халык киемен бизә”**

Уенның максаты: татар халык киеме силуэтында бизәк төзү.

Уенның бурычлары: төзи белү эшчәнлеген үстерү; татар орнаменты исемнәре белән балаларның сүзлеген баету, вак бармак һәм күз координациясе моторикасын үстерү; Татар халкы тарихы һәм традицияләренә кызыксыну тәрбияләү.

Уен кагыйдәләре: уенда татар халык киеме силуэты, татар орнаменты элементлары кулланыла.

1вариант. Һәр уенчы берешәр силуэт ала һәм татар орнаменты элементларыннан бизәк төзи.

2 вариант. Уенчыга бизәкләр урнаштырылган бер кием силуэты бирелә, уенчы үзендәге силуэтта шундый ук бизәк төшерергә тиеш була.

**Д/у “Бизәкне җый”**

Максат: мари халкының милли бизәк үрнәкләре белән таныштырып, аларның бизәү алымы, төс һәм фигура үзенчәлекләрен игътибарга алып кисәкләрдәнербөтен бизәк җыю.

Уенның бурычлары: кисәкләрдән бербөтенне җыярга өйрәтү; күреп истә калдыру сәлатен, игътибарлылыкны, вак бармак моторикасын үстерү; мари халкы традицияләренә кызыксыну тәрбияләү.

Уен барышы: балалар алдында өстәлдә мари халык бизәкләре төшерелгән төрле кисмә рәсемнәр ята. Тәрбияче балаларга кисәкләрдән бербөтен рәсем җыярга тәкъдим итә. Биремне үтәгәннән соң, балаларга үзләре җыйган сурәтне конверттагы сурәт белән чагыштырырга тәкъдим ителә. Уенда бердән алып өчкә кадәр бала катнаша ала.

**Д/у “ Курчакны киендер”**

Максат: идел буе халык (татар, рус, мари, удмурт) киемнәре,бизәлешләре турында балаларның белемнәрен камилләштерү.

Уенның бурычлары: идел буе халыкларының кием бизәлеше үрнәкләре белән таныштыру; бизәлеш алымнары турында белемнәрне камилләштерү; идел буе халыкларының традицияләренә кызыксыну тәрбияләү.

Уен барышы: уенда 2-4 бала катнаша ала. Балаларга малай һәм кыз курчагы силуэтлары бирелә. Өстәлдә төрле төстәге, идел буе халкы бизәкләре төшерелгән кышкы, җәйге киемнәр. Балалар үз теләкләре буенча малай һәм кыз курчагын киендерәләр.

**«Татарстан флагы»**

(тәрбиячеләр өчен мастер –класс)

*Садикова Р. Р., югары кв. категорияле тәрбияче,*
*Гыйззатуллина Г. И., югары кв. категорияле тәрбияче,*
*34 нче санлы "Салават күпере" балалар бакчасы, Алабуга шәһәре.*

**Максат:** педагогларга мәктәпкәчә яшьтәге балаларны Татарстан Республикасы флагы белән таныштыруда эзләнү эшчәнлеге технологиясен тәкъдим итү.

**Алдан эшләнгән эш:** җиһазлар әзерләү, әлеге тема буенча махсус әдәбият белән танышу.

**Җиһазлар:** һәр педагог өчен "1", "2", "3" саннары ябыштырылган өч һәм сан ябыштырмаган бер стакан; кызыл, яшел, ак төстәге буяулар һәм пумалалар; 6 кашык шикәр комы, аш кашыгы, болгату өчен таяк, шприц, стакан белән су.

**Гамәли әһәмияте:** әлеге мастер-класс мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән эшләүче тәрбиячеләргә һәм педагогларга кызыклы булырга мөмкин. Бигрәк тә "Эзләнүләр һәм тәҗрибәләр" темасы буенча эшләүче педагоглар үзләре өчен нинди дә булса яңалык табар, ә яңа эш башлаучылар моның ни дәрәҗәдә кызыклы һәм мавыктыргыч икәнен аңларлар дип уйлыйбыз. Мастер-класс барышында флагны ясау өчен барлык атрибутлар күрсәтеләчәк һәм һәр катнашучысы аны үзе ясап карый алачак.

Үз Ватанының тарихына һәм мәдәниятенә, аның дәүләт символикасына ихтирамсыз, тулы кыйммәтле шәхес тәрбияләү мөмкин түгел. Татарстан Республикасы дәүләт символикасын хаклы рәвештә Россия территориаль символикасы хәзинәсе дип санарга мөмкин. Һәм үз республикасын яраткан һәм хөрмәт иткән һәр татарстанлы Гербыбызның ничек күренүен, Гимнны һәм флагның төсләрен белергә тиеш. Безнең фикеребезчә, бүгенге көндә дәүләт символикасын белмәү проблемасы бик актуаль. Дәүләт символикасы турында мәгълүмат шактый күп, без аның турында телевидение аша да, туган шәһәр урамнарында да еш күрә яки ишетә алабыз. Балалар бакчасында да шулай ук Татарстан Республикасының дәүләт символларына зур игътибар бирелә.

Безнең алда әлеге юнәлеш буенча эшне нәтиҗәле һәм мавыктыргыч итеп үткәрү бурычы тора. Шул уңайдан без үз эшебездә төрле технологияләр, формалар, методлар һәм алымнар кулланабыз. Без бүген сезгә эзләнүләр һәм тәҗрибәләр аша Татарстан Республикасының флагы белән таныштыруның бер төрен тәкъдим итәбез. Балалар тәҗрибәләрне бик яраталар. Чөнки бу аларга күрсәтмә – образлы фикерләү хас булуы белән аңлатыла.

**Мастер-класс барышы:**

**1 нче этап.**

Һәр стаканга төрле күләмдә шикәр өстибез: 1нче номерлы стаканга 1 аш кашыгы, 2 нче номерлыга 2 аш кашыгы, 3 нче номерлыга 3 аш кашыгы.

**2 нче этап.**

Һәр стаканга өчәр кашык су өстибез.







**3 нче этап.** Җентекләп болгатабыз.

**4 нче этап.**

Буяулар өстибез.Һәр стаканга буяулар өстибез: 1нче номерлы стаканга – яшел, 2 нче номерлы стаканга - ак, 3 номерлы стаканга – кызыл.







**5 нче этап.**

Флаг ясый башлыйбыз. Хәзер иң кызыгы. Энәсез генә шприц ярдәмендә чиста стаканга ясаган төсле сыекчаларны (3 нчедән башлап, чөнки анда шикәр күбрәк) өсти башлыйбыз,тәртип буенча барабыз (кире исәптә). Стакан стенасының кырыеннан коярга тырышабыз.







**Нәтиҗә:** Стаканда 3 төрле катлам – иң түбәне кызыл, аннары ак һәм яшел барлыкка килә. Алар кушылмыйлар. Һәм менә шундый буйлы, якты һәм матур **ТР флагы** килеп чыга.

**Тәҗрибәнең сере:** Һәр сыеклыкта шикәрнең концентрациясе төрле иде. Шикәр күбрәк булган саен, су тыгызлыгы да югарырак, ул «авыррак» һәм бу катлам стаканда түбәнрәк була.



**«Патриот своей Родины»**

(сценарий развлечения по патриотическому воспитанию с детьми старшей группы

*Абзалтынова Г. Н., воспитатель*
*МБДОУ Кутлу-Букашский детский сад «Дуслык»*
*Рыбно-Слободского муниципального района РТ*

**Цель:** закрепить и обобщить знания о России, о государственной символике России, развивать чувство патриотизма и любви к своей Родине.

**Задачи.**

**Образовательные:** формировать у детей представление о Родине.

**Развивающие:** развивать познавательный интерес детей, расширять кругозор.

**Воспитательные:** воспитывать любовь к Родине, гражданско– патриотические чувства.

**Предварительная работа:** беседы о российской символике и рассматривание иллюстраций по теме; чтение стихотворений, пословиц и поговорок о Родине, обсуждение их значений; рассматривание фотографий городов и рек нашей страны.

**Ход развлечения.**

Дети заходят под музыку «Я, ты, он, она вместе целая страна» Непоседы.

**Воспитатель:**

Родина! А что это такое? Каждый человек это понятие представляет по-своему. Для кого-то это определенный город, село или деревня. Для кого-то дом и двор, где родился и, где прошло детство. Хлеб, которым человек кормится, земля, на которой человек живёт, мать, которая даёт жизнь… Без всего этого, человеку жить просто невозможно. Среди самого необходимого, самого дорогого, есть у человека Родина!

**Воспитатель:** Очень много поэтов и писателей написали много произведений про родину.

Что мы Родиной зовём?
Дом, где мы с тобой живём,
И берёзки, вдоль которых
Рядом с мамой мы идём.
Что мы Родиной зовём?
Поле с тонким колоском,
Наши праздники и песни,
Тёплый вечер за окном.
Что мы Родиной зовём?
Всё, что в сердце бережём,
И под небом синим-синим
Флаг России над Кремлём.

**В. Степанов**

**Воспитатель:** Ребята, а что для вас значит Родина?

**Ребёнок:**

Родина слово большое, большое!
Пусть не бывает на свете чудес,
Если сказать это слово с душою,
Глубже морей оно, выше небес!

**Ребёнок:**

В нем умещается ровно полмира:
Мама и папа, соседи, друзья.
Город родимый, родная квартира,
Бабушка, школа, котенок … и я.

**Ребёнок:**

На широком просторе
Предрассветной порой
Встали алые зори
Над родимой страной.

С каждым годом всё краше
Дорогие края...
Лучше Родины нашей
Нет на свете, друзья!

**Воспитатель:** Конечно, слово Родина, означает очень многое, и каждый понимает его по-своему. Родина – это и земля, и страна в которой мы родились. Это и мать, и отец твой.

**Игра: «Продолжи пословицу»**

1. Жить - Родине служить.
2. Кто за Родину горой, тот и герой.
3. Дома и стены помогают.
4. В гостях хорошо, а дома лучше.
5. Всякий кулик свое болото хвалит.
6. Родной край – сердцу рай.
7. Без корня трава не растёт, без Родины человек не живёт.
8. На чужбине и калач не в радость, а на родине и чёрный хлеб в сладость.
9. Мать кормит детей….как земля людей.
10. Птица радуется весне….а младенец матери

**Воспитатель:** Вы большие молодцы, ребята.

А теперь исполним все вместе нашу любимую песню про Родину.

***Дети исполняют песню*«Песня о Родине»***сл.Е.Карасевой, муз.В.Елинека*

**Воспитатель:**

Ребята, скажите, как называется наша страна? *(Ответы детей)*

**Воспитатель:**

Правильно, молодцы, мы с вами живём в России. Россия подобна огромному дереву ,на котором не сосчитать листьев, но всякое дерево имеет корни. Листья – это мы, корни - это наше прошлое, наша история, наши деды, прадеды. Человеку надо знать свои корни, историю своей Родины, государства. И тогда такой человек может назвать себя: «Я - гражданин своей Родины. Я – патриот!»

**Воспитатель:**

А что такое малая Родина? *(Ответы детей)*

У каждого человека на земле есть место, где он родился. Здесь впервые он увидел мамины глаза и улыбку, ласковые лучи солнца, зеленую траву, голубое небо. Это место называется - Малая Родина! Малая Родина - это место, где живут близкие и дорогие нам люди. Малая Родина-это место, где стоит наш детский сад. Малая Родина для нас – д.Кутлу-Букаш.

**Воспитатель:** А сейчас мы поиграем с вами в игру. Я вам буду показывать известные места нашего села, где вы часто бываете, где бывают ваши родители. Вы должны узнать это место, сказать, как оно называется.

**Проводится игра «Посмотри и узнай» (показ презентации на экране)**

- Здорово! А давайте теперь так поиграем, я буду говорить начало, а вы будет продолжать…

Наша страна называется – ***Россия.***
Торжественная песня страны называется - **Гимн**
Граждане России, т.е. мы с вами – ***Россияне***
Как называется Республика в которой мы живём» **- Республика Татарстан**
Из каких цветов состоит флаг России? – **Белый синий красный.**

А из каких цветов состоит флаг нашей республики?-**Зеленый,белый,красный**
Они означают- **(белый – чистота;синий – вера и верность, искренность, совершенство; красный - мужество, сила и кровь, пролитая призащите Родины).**
Столица России город – ***Москва***
Давайте все вместе ей скажем *«Ура».*
Дети исполняют песню *«С чего начинается родина»*

***Ребенок:***

Жура-жура-журавель!
Облетал он сто земель.
Облетал, обходил,
Крылья, ноги натрудил.
Мы спросили журавля:
Где же лучшая земля?
Отвечал он, пролетая:
Лучше нет родного края!

**Ребенок:**

Поезжай за моря-океаны,
Надо всею землёй пролети:
Есть на свете различные страны,
Но такой, как у нас, не найти.
Глубоки наши светлые воды,
Широка и привольна земля,
И гремят, не смолкая, заводы,
И шумят, расцветая, поля...

**Ребенок:**Слышишь песенку ручья?
Это — Родина твоя.
Слышишь голос соловья?
Это — Родина твоя.Руки матери твоей,
Звон дождей, и шум ветвей,
И в лесу смородина —
Это тоже родина.

**Воспитатель:** Славились на Руси и народные игры – забавы. Богатыри мерились своей богатырской силой. Давайте – ка и мы посмотрим на наших богатырей!

**Игра «Перетягивание каната».**

**Воспитатель:** А теперь посмотрим на наших рукодельниц. Девочки наматывают нитки в клубок.

**Воспитатель:**

Если скажут слово «Родина»,
Сразу в памяти встаёт
Старый дом, в саду смородина,
Толстый тополь у ворот.
У реки берёзка-скромница
И ромашковый бугор…
А другим, наверно, вспомнится
Свой родной московский двор…
В лужах первые кораблики,
Над скакалкой топот ног

И большой соседней фабрики
Громкий радостный гудок.
Или степь от маков красная,
Золотая целина…
Родина бывает разная,
Но у всех она одна!

**И сейчас для нас с вами прозвучит Гимн Великой нашей державы.**

**Воспитатель**: Вот и подошёл к концу наш праздник! Мы желаем вам здоровья, счастья, преданных и верных друзей. И, конечно же, быть патриотами, любить и защищать свою Родину, своих родных и близких. С праздником!

## «Хэтер түштамгасы»

*(тәрбиячеләр һәм эти-әниләр өчен мастер-класс)*

*Гафурова Л.И., беренче кв. категорияле тәрбияче,*
*Шигаева Л.М., югары кв. категорияле тәрбияче,*
*Гареева Л.И., югары кв. категорияле тәрбияче,*
*34 нче санлы "Салават күпере" бабалар бакчасы, Алабуга шәһәре*

Мастер – класс тәрбиячеләр һәм эти-әниләр өчен исәпләнгән.

**Максаты:** Халкыбыз традицияләрен, йолаларын, гореф-гадәтләрен һәм туган телебезгә аерым игътибар булырга тиешлеген төшендерә алу тора.

**Бурычлар:**

1)Халкыбыз тарихына кызыксыну уяту.
2)Ветераннарга, патриотик тәрбиягә хөрмәт тәрбияләү.
3)Түштамга ясауның яңа ысуллары белән таныштыру.

**Мастер – классның әһәмияте:** "Георгий лентасы"- ул хәтер ясагы. Тынычлыкны яклап сугышканда югалган солдатларны искә алу, ветераннарга хөрмәт символы, Бөек Ватан сугышында җиңү белән горурлану һәм үз гомерләре бәрабәренә сугыш кырында тынычлыкны саклап сугышкан солдатларга рәхмәт әйтү билгесе дә булып тора. "Минем истә, мин горурланам!" дигән девиз астында "Георгий тасмасы" кулланып мастер-класс оештырдык. Аның төп максаты – яшь буынга коточкыч сугышта җиңү кайтавазын онытырмау, андагы каһарманнарга дан җырлау.

Бу тасмалардан ясалган "Түштамга"ларга карап, һәркем үз Героеын искә ала, чөнки илебездә сугыш кагылмаган бер генә гаилә дә юк. Җиңүчеләр турында тарихи истәлекләрне саклап калу безнең изге бурычыбыз.

**Җиһазлау:** хәтер лентасы, өлге-йолдыз, 50см. кызыл төтәге тасма, синельный чыбык, челтәр, булавка, клей, кайчы, салфетка, таякчыклар, инә, җеп, видео язма.

**Мастер – класс барышы:**

Исәнмесез хөрмәтле хезмәттәшләр, хәерле көн! Безнең бакчабызда 2019 елдан бирле "Алтын куллар" дип аталган эти-әниләр клубы эшләп килә. Без бүгенге мастер – классыбызда хөрмәтле кунаклар, әниләр сезгә җиңүнең 80 еллыгы уңаеннан хәтер түштамгасы ясарга өйрәнербез. Ә хәзер мастер – классыбызда иң актив катнашучы Фарида Фаизовнага сүзне бирәбез.

***Төп өлеш:***

Эшебез 6 өлештән торачак.

1. Мастер – класска кирәкле материаллар.



2.Хәтер тасмасыннан тамчы формасы бөкләп ясау.



3.Өлге ярдәмендә “йолдыз” ясап хәтер тасмасына урнаштыру.



4.50см атлас лентадан җыерттырып канәфер чәчәкләре ясау.



5. Канәфер чәчәкләрен йөлдыз эченә урнаштыру.



6. Синельный чыбык ярдәмендә канәфер чәчәгенә яфракларын ясау һәм йолдыз эченә урнаштыру.



7. Түштамгабызның арткы ягына булавканы ябыштырып кую.



***Йомгаклау:***

Карагыз әле безнең нинди матур түштамга килеп чыкты.

Сез аны җиңүнең 80 еллыгы 9май бәйрәменә тагарсыз дип ышанып калабыз. Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт! Мастер – классыбыз сезгә ошагандыр дип уйлыйбыз.



## «Путешествие по России»

*(конспект образовательной деятельности)*

*Балякина Л. В., воспитатель первой кв.категории*
*МБДОУ ДС №2 «Кояшкай» г. Мамадыш*

Цель. Развивать у детей патриотические чувства, Воспитывать любовь к Родине.

Задачи:

Уточнить и углубить знания и представления дошкольников о России как государстве, в котором они живут, о республике Татарстан.

Формировать уважительное отношение к государственным символам.

Уточнить и закрепить знания детей о «малой Родине», учить раскрывать это понятие. Называть достопримечательности, памятники города Мамадыш.

Воспитывать любовь и уважение к своей стране, малой Родине.

Предварительная работа: Беседы о символике России и Татарстана; чтение и разучивание стихотворений о Родине, родном городе ;рассматривание альбома «Мамадыш. Все о городе своем», прогулка по центральной улице города (Советская); чтение пословиц и поговорок; рассматривание фотографий и иллюстраций на данную тематику.

Материал: фотографии зданий и объектов города Мамадыш.

Ход занятия:

Воспитатель читает стихотворение З.Александровой «Родина».

Если скажут слово « Родина»
Сразу в памяти встает:
Старый дом, в саду смородина,
Толстый тополь у ворот,
У реки березка- скромница
И ромашковый бугор…
А другим, наверное, вспомнится
Свой родной московский двор.
В лужах первые кораблики
Над скакалкой топот ног,
И большой соседней фабрики
Громкий радостный гудок.
Или степь от маков красная,
Золотая целина…
Родина бывает разная,
Но у всех она одна!

Воспитатель: Ребята, скажите, о чем это стихотворение?

Дети: О Родине.

Воспитатель: Правильно. Сегодня мы с вами поговорим о Родине. Ребята, объясните, как вы понимаете, что такое «Родина»? Дети: Родина- это место, где мы родились; страна в которой мы живем).

Воспитатель: Родина – это и дом, в котором мы живем, и наши предки, наши мамы, папы, бабушки и дедушки, подарившие нам жизнь. И город со своими улицами и парками. А в какой стране мы с вами живем?

Дети: В России.

Воспитатель: Да, Россия великая, могучая держава. Про неё можно сказать много красивых слов. Давайте и мы назовем эти слова и поиграем в игру «Передай сердечко» (дети передают сердечко и называют по одному прилагательному к слову Родина. Например: милая, красивая, любимая, родная, единственная, сильная, могучая, чудесная, дорогая, хорошая).

В: Я предлагаю отправиться в путешествие на автобусе, который нас уже ждёт. Позвольте мне сегодня быть вашим гидом и сопровождать вас на протяжении всей поездки.

Воспитатель: Но для того, чтобы занять места в салоне, надо приобрести билеты. Цена вашего билета -улыбка.

*1 остановка «Государственная»*

**Воспитатель:** А сейчас мы поиграем в игру

**«Вопрос- ответ!» (игра в кругу с мячом)**

**Вопросы:**

1. Как называется столица нашей Родины?
2. Кто является президентом России?
3.В какой республике мы живем?
4. Как называется главный город нашей республики?
5.Назовите раиса Республики Татарстан?
6. Назовите цвета флага России.
7. Назовите цвета флага Татарстана.
8. Как называется город в котором мы живем?
9.Что изображено на гербе нашего города?

Воспитатель: Наше путешествие продолжается. Следующая остановка «Моя малая Родина».

*2 Остановка «Моя малая Родина»*

Воспитатель: Ребята,как вы думаете, что такое малая Родина?

Дети(ответы).

Воспитатель: У каждого из нас есть своя малая родина — тот уголок земли, где мы родились, где прошло наше детство, где живут наши родители, где находится наш родной дом. Для кого-то малая родина — небольшой поселок или деревушка, для других — городская улица и зеленый дворик с качелями, песочницей и деревянной горкой. Словом, малая родина у каждого своя!

Любить можно только то,что хорошо знаешь. Чем больше мы будем знать о нашем городе,тем больше мы будем его любить.

История города и района тесно переплетается с историческими событиями и именами знаменитых людей. По легендам, даже царица Сююмбике приезжала сюда на отдых.

Мамадыш впервые упоминается в летописях в 1151 году. Из них видно, что между Мамадышем и Киевской Русью существовали торговые связи.

Страницы древних рукописей и старинные предания рассказывают, что Мамадыш появился очень давно. В одной из наиболее достоверных и распространенных поныне легенд говорится: "...старик Мамадыш остановился на реке Нукрат (Вятка) и стала деревня Мамадыш". То есть, название нового поселения на реке Вятка связывается с именем человека, его основавшего: имя собственное - Мамдяш, Мамяш было широко распространено среди булгарского населения./ Эта дата и берется за год основания современного города Мамадыша

Ребята,а как называется главная улица нашего города?

На какой улице находится наш детский сад?

Что находится рядом с детским садом?

Как называется улица на которой ты живешь?

А сейчас я предлагаю вам поиграть . Игра называется « Моя малая Родина».Воспитатель: Ребята ,наш город очень красивый. В нашем городе много красивых зданий. Назовите их.

1.Один из игроков втягивает карточку ,не показывая ее другим, описывает данный объект так чтобы другие игроки смогли угадать.

2.Ведущий раскладывает перед собой в ряд несколько фотографий ,игроки рассматривают и запоминают фотографии. Затем игроки закрывают глаза, а ведущий убирают одну из фотографий . Задача игроков назвать какой фотографии не стало.

*3 Остановка «Белая береза»*

**Воспитатель:** ребята, у каждой страны есть государственные символы. Какие государственные символы России вы знаете? (флаг, герб, гимн)

**Воспитатель:** верно, это государственные символы России. Но есть еще негосударственные символы. Как вы думаете, какие? (берёза и ромашка, и др.).
Ребята я предлагаю вам нарисовать березку .(Нетрадиционная техника рисования. На темном картоне дети рисуют березку клеем, затем посыпают ее манной крупой.)

*4 Остановка « Народные умельцы»*

Воспитатель:В России и Татарстане проживали народные умельцы,которые шили очень красивую одежду и украшали ее национальными узорами.
Какую русскую национальную одежду вы знаете?(сарафан,кокошник,рубаха ит.д)
Назовите татарскую национальную одежду(калфак,камзол,ичиги и т.д)
Я предлагаю вам ребята побыть сегодня стать такими же умельцами и украсить одежду русского и татарского народа,элементами национальных узоров.
*Проводится игра « Укрась национальную одежду»*
Наше путешествие закончилось.
На каких станциях мы сегодня побывали?
О чем разговаривали?
Что вам больше всего понравилось?
Молодцы ребята. Вижу, что вы все любите свою страну и малую Родину- свой город. Вы настоящие патриоты своей страны.

## «Символы России»

(конспект образовательной для детей старшей группы деятельности)

*Абрамова О. А., музыкальный руководитель первой кв. категории*
*Хусаинова А. Р., воспитатель первой кв. категории*
*МБДОУ - «ДС №87 «Золушка», г. Набережные Челны*

**Задачи:**

- *развивающие:* развивать диалогическую форму речи; совершенствовать представления детей о государственной символике и формирование эстетического отношения к народным символам России;
- *воспитательные:* воспитывать у детей патриотические чувства к Родине: любовь, уважение к родной стране, бережное отношение к ней;
- *обучающие:* обобщить и систематизировать знания детей о Родине – России; закрепить знания о флаге, гербе, гимне, березе, народных символах; совершенствовать художественно-речевые исполнительские навыки детей при чтении стихов закрепить умение создавать образ берёзки в технике обрывной аппликации; расширить представления детей о березе как символе России;

**Предполагаемый результат:** дети будут знать официальные символы России (флаг, герб, гимн России) и неофициальные (медведь, береза, ромашка, самовар, балалайка, гармонь, матрешка, хохлома), природу родных мест, любоваться природой, бережно относиться к ней; пополнение словарного запаса детей пословицами и поговорками о своей Родине; у детей формируется умение создавать объемную аппликацию, путем наклеивания листьев березы, а также используя пластилинографию.

**Виды детской деятельности:** игровая, познавательная, двигательная, коммуникативная.
**Индивидуальная работа:** заучивание стихов о Родине
**Словарная работа:** государственные символы, Родина, Отчество, Россия, герб, флаг, гимн, скипетр, держава.
**Оборудование:** интерактивная доска, ноутбук
**Демонстрационный, раздаточный материал:** слайды и видеоматериалы по теме иллюстрация российского флага, герба РФ, запись гимна РФ, деревянные ложки, матрешки,

бубны; картон синего цвета; клей и кисточки для клея; тарелочки с заготовками пластилина белого, черного цвета. Бумага зелёного цвета для аппликации; салфетки, клеёнки на каждого ребёнка.

**Ход ООД:**

Дети заходят под музыку "Марш"(Д.Шостакович)

**Педагог**: Здравствуйте ребята! Нашу встречу, мы начнем с музыкально-ритмического упражнения "Вышли на парад" муз. В. Найденова.

**Педагог:** На планете много разных стран, но самая большая - наша страна. Как она называется?

**Ответ детей:** Россия

**Педагог:** Правильно, Россия. Какая она, наша Россия? А вот это мы сейчас увидим. Я приглашаю, вас, в необычное видео-путешествие.

*Презентация «Моя Россия». (презентация сопровождается песней «Моя Россия», муз. Г.Струве, сл.Н.Соловьева)*

**Педагог:** Россия – наша Родина. Ребята, объясните, как вы понимаете, что такое *«Родина»*?

**Ответ детей:** Родина – место, где мы родились; страна, в которой мы живем. Родина у каждого человека одна и т. д)

**Дети:**

1. Что мы Родиной зовём?
Дом, где мы с тобой живём,
И берёзки, вдоль которых,
Рядом с мамой мы идём.
2. Что мы Родиной зовём?
Поле с тонким колоском,
Наши праздники и песни,
Тёплый вечер за окном.
3. Что мы Родиной зовём?
Всё, что в сердце бережём,
И под небом синим-синим
Флаг России над Кремлём.

**Педагог**: У каждой страны есть свои государственные символы. Назовите государственные символы России. *(Герб, флаг, гимн.)*

**Педагог:** Флаг России трехцветный: белый цвет – цвет мира и чистоты, синий – цвет неба, верности и правды, красный – цвет огня и отваги.

Герб – символ нашего государства. Фон герба красный – символ жизни, крылья золотого орла, словно лучи солнца. На груди орла изображен всадник – Георгий Победоносец. Он на белом коне, за плечами синий плащ. Его конь топчет черного дракона – символ зла. Изображение Георгия Победоносца говорит нам, что кто придет к нам с мечом, от меча и погибнет.

У каждого государства есть свой гимн. Это торжественная песня, которая исполняется в особо торжественных случаях.

**Педагог:** Сейчас мы послушаем отрывок гимна России.

*(Звучит отрывок гимна. Все слушают его стоя.)«Гимн РФ» муз. Михалкова сл. Александрова*

**Педагог:** Ребята, скажите какой характер у гимна *(величественный, торжественный, который прославляет нашу страну)*

**Педагог:** Ребята, вы гордитесь своей страной? Поэты и композиторы о нашей Родине написали много песен, которые прославляют нашу русскую землю. С одной из таких песен мы с вами познакомимся. Послушайте её.

*«Самая любимая Родина моя» муз.и сл. Понамаревой*

**Педагог:** А сейчас мы попробуем спеть, но для начала мы должны распеть
